КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 26 март г.Казань № 220

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт, шул исәптән хәрби, һәм белем бирү эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе булган шәхси мәгариф оешмаларының аспирантлары, адъюнктлары, студентлары һәм курсантлары өчен Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендиясе турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1012 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт, шул исәптән хәрби, һәм белем бирү эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе булган шәхси мәгариф оешмаларының аспирантлары, адъюнктлары, студентлары һәм курсантлары өчен Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендиясе турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1012 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган

в составе Дәүләт, шул исәптән хәрби, һәм белем бирү эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе булган шәхси мәгариф оешмаларының аспирантлары, адъюнктлары, студентлары һәм курсантлары өчен Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендиясе буенча комиссия составында:

Комиссия составыннан Р.М.Гарифуллинны, В.В.Усановны, Р.И.Замановны, Н.Н.Маливановны, В.В.Майстренконы, Э.Э.Искәндәревне чыгарырга;

Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрының беренче урынбасары, комиссия рәисе урынбасары Тимур Җәүдәт улы Сөләймановны;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының коммерциягә карамаган оешмалар һәм яшьләр оешмалары белән эшләү бүлеге башлыгы, комиссиянең җаваплы секретаре Дениса Викторович Сугоняконы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәр белеме бирү һәм фән бүлеге башлыгы Андрей Андреевич Выборновны;

«Татарстан Республикасы Студентлар лигасы» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы президенты Руфат Рифгать улы Кыямовны (килешү буенча);

Россия Федерациясе Оборона министрлыгының хәрби белем бирүче «Кызыл байраклы Казан югары танк команда училищесы» федераль дәүләт казна мәгариф учреждениесе башлыгы Кирилл Денисович Кулаковны (килешү буенча);

югары белем бирүче «А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең белем бирү эшчәнлеге буенча проректоры Алексей Александрович Лопатинны (килешү буенча);

Комиссия әгъзалары вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Гафуров Илшат Рәфкать улы | Татарстан Республикасы югары уку йортлары ректорлары советы рәисе, югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном учреждениесе ректоры, комиссия рәисе (килешү буенча) |
| Бикеев Игорь Измаилович | югары белем бирүче «В.Г.Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (ИЭУП)» шәхси мәгариф учреждениесенең беренче проректоры, фәнни эшләр буенча проректоры, җинаять хокукы һәм процессы кафедрасы профессоры (килешү буенча) |
| Җәләлова Анфиса Григорьев | «Татарстан Республикасының урта һөнәри белем бирүче мәгариф учреждениеләре директорлары советы» коммерциягә карамаган партнерлыгы рәисе, «Казан педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Кондратьев Андрей Станиславович | «Бердәм Россия» бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлегенә караган Төбәк башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Лоханов Николай Павлович | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсендәге кадрлар, тәрбия эшләре, һөнәри әзерлек һәм психологик тәэмин итү бүлеге башлыгы (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин